| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘХМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

29 март 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 10 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Үзәк урамы, 51нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Нагорная урамында яшәүче гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2024 елның 10 апрелендә 10 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Үзәк урамы, 51нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Мәктәп, Заречная урамында яшәүче гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2024 елның 10 апрелендә 11 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Үзәк урамы, 51нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Новая, Үзәк урамнарында яшәүче гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2024 елның 10 апрелендә 13 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Ягодная урамы, 11нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Ягодная урамында яшәүче гражданнар Җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Сез элек расланганнарга үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Аксумла авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 13.11.2023 ел 1 карары

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Аксумла авылында гражданнар Җыенының 13.11.2023 ел, № 2 карары,

түбәндәге редакциядә раслап:

«Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, 85 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнар, СВОда катнашучылапрдан тыш һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

Аксумла авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге үтүләрне ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Аксумла авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова